**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**

**КАРАР** №21

III чакырылышның чираттан тыш утырышы | Урыссу ш.т.б. | “26” июнь 2018нче ел.

*Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесенең вазифаи вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү Тәртибе турында*

Россия Федерациясенең хезмәт кодексына, 2003 елның 6 октябреннән булган “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 санлы, 2008 елның 25 декабреннән булган “Коррупция белән көрәш турында”гы 273 санлы Федераль Законнарына, Татарстан республикасы Ютазы муниципаль районы Уставына ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесенең вазифаи вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү Тәртибен расларга (Кушымта).
2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына:

2.1. әлеге карар белән ведомстводагы оешмалар (учреждениеләр) җитәкчеләрен таныштырырга;

2.2. хезмәт бурычларын үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында җирле үзидарә органы җитәкчесенә ведомстводагы оешма җитәкчесенең хәбәр итү бурычын билгеләгән үзгәрешләрне оешмалар (учреждениеләр) уставына, җирле үзидарә карамагындагы органнанрга, шулай ук аларның җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт килешүләренә кертергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәренең Рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4.Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, регламент һәм җирлек Советлары белән эшләү буенча комиссиягә йөкләргә.

Ютазы муниципаль
районы Башлыгы,
Ютазы район Советы Рәисе Р.М. Нуриев.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Советы
карарына Кушымта
_____2018 ел №__

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы органы (учреждениесе) җитәкчесенең ведомстводагы җирле үзидарә органына вазифаи вәкаләтләрен үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итүе тәртибе**

1.Әлеге Тәртип ведомстводагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарәсе органына оешма (учреждение) җитәкчесенең вазифаи вәкаләтләрен үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итү процедурасын регламентлый.

2. Әлеге Тәртиптә мәнфәгатьләр каршылыгы дигәндә, вазифасы мәнфәгатьләр каршылыгына юл куймау һәм аны җайга салу буенча чаралар күрүне күздә тоткан затның шәхси (турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган) кызыксынучанлыгы аның тарфыннан тиешенчә, объектив һәм вазифаи (хезмәт) бурычларын (вәкаләтләрен) башкаруга тәэсир итә торган яки тәэсир итәргә мөмкин булган вазгыятьне аңларга кирәк.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе, Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәш буенча закончалыгына һәм оешма (учреждение) уставына ярашлы, мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүе турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр каршылыгына юл куймау яки җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе эш белән тәэмин итүчегә (эшкә алучы вәкиленә) хезмәт бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында бу турыда аңа билгеле булган көннән соң, бер эш көненнән соңламыйча хәбәр итәргә тиеш.

5. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән срокта мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында ведомстводагы учреждение (оешма) җитәкчесенә бәйләнмәгән сәбәпләр аркасында хәбәр итәргә

мөмкин булмаган очракта, хәбәр, ул бетерелгәннән соң, бер эш көненнән соңламыйча җиткерелә.

6. Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык тууы турында белдерү язма формада белдерүнамә төрендә (алга таба – белдерүнамә) рәсмиләштерелә.

Белдерүнамәдә түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

а) белдерүнамәне тутырган ведомстводагы оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы;

б) ведомстводагы оешма җитәкчесенең шәхси кызыксынучанлыгы аның тарафыннан хезмәт бурычларын тиешенчә, объектив һәм гадел үтәүгә тәэсир иткән яки тәэсир итәргә мөмкин булган (турыдан-туры яки турыдан-туры түгел) вазгыятьне тасвирлап язу;

в) ведомстводагы оешма җитәкчесенең хезмәт вазифаларын тиешенчә үтәвенә тәэсир иткән яки тәэсир итәргә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыкны квалификацияләүче билгеләр (акча төрендә табыш, башка милек, шул исәптән милек хокукы, милек характерындагы хезмәтләр, ведомстводагы оешма җитәкчесе һәм (яки) аның белән якын туганлыкта яки кардәшлектә (свойство) торган затлар (әти-әни, ир белән хатын, балалар, эне-абыйлар, апа-сеңелләр, ирнең яки хатынның әти-әнисе, эне-абыйлары, апа-сеңелләре һәм балалары яки балаларның ирләре яки хатыннары) белән башкарылган эш нәтиҗәләре яки нинди дә булса файда (өстенлек) алу мөмкинлеге, яки ведомтсводагы зат якын туганлыкта яки кардәшлектә торган, мөлкәти, корпоратив яки башка якын мөнәсәбәтләр белән бәйле гражданнар яки оешмалар);

г) шәхси кызыксынучанлык аларны башкарырга негатив тәэсир иткән яки итәргә мөмкин булган хезмәт бурычларын күрсәтү;

д) мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә юл куймаслык яки барлыкка килгән мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салырлык тәкъдим ителгән чаралар;

е) белдерүнамәне тутыру датасы;

ж) белдерүнамәне тутырган затның имзасы.

7. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органына караган оешма (учреждение) җитәкчесе эш белән тәэмин

итүчегә (эшкә алучы вәкиленә) 1санлы кушымтага ярашлы форма буенча төзелгән белдерүнамә җибәрә.

8. Эш белән тәэмин итүче (яэшкә алучы вәкиле) адресына кергән белдерүнамә тикшерү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының хезмәттә (вазифаи) үзеңне тотыш таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиягә (алга таба – Комиссия) җибәрелә.

9. Белдерүнамәне теркәү Комиссия секретаре тарафыннан аларны теркәү журналында гамәлгә ашырыла, аның тәкъдим ителгән үрнәге әлеге Тәртипнең 2 санлы кушымтасында каралган.

Комиссия секретаре белдерүнамәдә язылган мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга бурычлы. Конфиденциаль мәгълүматны таратуда гаепле зат дисциплинар, Россия Федерациясе закончалыгына ярашлы, башка җаваплылык тота.

10. Белдерүнамәнең күчермәсе теркәү турында билге куелып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма җитәкчесенең кулына, белдерүнамәләрне теркәү журналында, алуын раслаган имзасын куйдыртып, тапшырыла яки почта аша алу турында белдерүнамә җибәрү шарты белән юнәлтелә.

11. Белдерүнамәләрне алдан карау барышында, Комиссия билгеләнгән тәртиптә аларда бәян ителгән шартлар буенча белдерүнамәне җибәргән затлардан аңлатмалар алырга һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт власте федераль органнарына, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга запрослар җибәрергә хокуклы.

12. Белдерүнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча, аларның һәрберсенә нигезле нәтиҗә әзерләнә.

Белдерүнамәләрне алдан тикшерү барышында алынган белдерүнамәләр, нәтиҗәләр һәм башка материаллар белдерүнамәләр кергән көннән соң җиде эш көне дәвамында Комиссия утырышына тәкъдим ителә.

Әлеге тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән запрослар җибәрү очрагында, белдерүнамәләр, нәтиҗәләр һәм башка материаллар Комиссиягә белдерүнамәнең эш белән тәэмин итүчегә (эшкә алучы вәкиленә) кергән көненнән соң, 45 көн дәвамында дәвамында  алып киленә. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артык түгел.

13. Комиссия белдерүнамәләрне карый һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының ____________нән булган _____санлы Кагыйдәнамәсе (Положение) белән расланган тәртиптә карарлар кабул итә һәм кабул ителгән карарны эш белән тәэмин итүчегә (эшкә алучы вәкиленә) җибәрә.

14. Эш белән тәэмин итүче (эшкә алучы вәкиле) белдерүнамәләрне комиссия каравы нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а)белдерүнамәне җибәргән затның вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килмәгәнлеген таный;

б) белдерүнамәне җибәргән затның вазифаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык мәнфәгатьләр каршылыгына китерүен яки китерергә мөмкин булуын таный;

в) белдерүнамәне җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгына юл куймау һәм (яки) аларны булдырмау буенча чаралар күрелмәвен таный.

15. Әлеге Тәртипнең 14 пункты “б” подпунктында каралган карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе закончалыгына ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарәсе органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе чаралар күрә яки мәнфәгатьләр каршылыгына юл куймау яки аларны җайга салу буенча чаралар күрүне тәэмин итә.

16. Әлеге Тәртипнең 14 пунктында “в” подпунктында каралган карар кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә Россия Федерациясе хезмәт кодексы, җирле үзидарә органы (учреждение) уставы һәм хезмәт килешүе белән каралган дисциплинар җәза кулланыла.

Белдерүнамә һәм аны карау белән бәйле башка материаллар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе шәхси эшенә (личное дело) теркәлә.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы<br>җирле үзидарәсе органы карамагындагы оешма<br>(учреждение) җитәкчесенең вазифаи вәкаләтләрен<br>үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки<br>китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык<br>барлыкка килүе турында хәбәр итү Тәртибенә<br>Кушымта №1

Тәкъдим ителгән үрнәк
Татарстан республикасы Ютазы муниципаль районы вәкаләтле органы рәисенә, башкарма комитеты җитәкчесенә (кирәклесен сайларга)
_______(Ф.И.А.)_________________
Кемнән _____(Ф.И.А., вазифасы)___

**Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә, мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында**

**БЕЛДЕРҮНАМӘ**

Вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә, миндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында хәбәр итәм (кирәклесенең астына сызарга).

Шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү өчен нигез булган шартлар:

---

---

Шәхси кызыксынучанлык аларның үтәлешенә йогынты ясый яки ясарга мөмкин булган вазифаи вәкаләтләр:

---

Мәнфәгатьләр каршылыгына юл куймау яки аны җайга салу буенча тәкъдим ителгән чаралар:

---

Әлеге белдерүнамәне карап тикшергәндә, Татарстан Республикасы (район исеме) муниципаль районы Комиссиясе утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) (кирәклесенең астына сызарга).

---

“__”_____ 20__ ел белдерүнамәне җибәргән кешенең имзасы ________

имзаның аңлатмасы (расшифровка подписи) _____________________

Татарстан республикасы Ютазы муниципаль районы
җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение)
җитәкчесенең вазифаи вәкаләтләрне үтәгәндә,
мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган
шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе
турында белдерүе Тәртибенә
Кушымта № 2

*Тәкъдим ителгән үрнәк*

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма җитәкчесенең эш белән тәэмин итүченең (эшкә алучы вәкиле) вазифаи вәкаләтләр үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китергән яки китерергә мөмкин**

**булган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында белдерүнамәләр теркәү**

**ЖУРНАЛЫ**

| N т/б | Белдерүнамәнең теркәү номеры | Белдерүнамәне теркәү датасы | Белдерүнамә алып килүче | | Белдерүнамә теркәлде | | | Белдерүнамә күчермәсен алу (күчермәне алдым, имза)яки почта аша белдерүнамә күчермәсе җибәрелү турында билгеләү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ф.И.А. | вазифасы | Ф.И.А. | вазифасы | Имзасы | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |